| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Крындинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кырынды авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.11.2023 Кырынды авылы № 4

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кырынды авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге Башлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кырынды торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2023 елның 27 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кырынды торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2023 елның 27 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кырынды торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын 2023 елның 27 ноябрендә 17 сәгать 00 минутка билгеләргә.

4. Халык исемлеген территориаль билгеләр буенча бүләргә:
- 1 этап: Кырынды авылы Киров ур., Совет ур. яшәүчеләр.
- 2 этап: Кырынды авылы К. Маркс ур., Полевая ур. яшәүчеләр.
- 3 этап: Кырынды авылы Кооператив ур., К. Маркс тыкрыгында яшәүчеләр.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2024 елда үзара салым акчаларын кертү өчен «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль

берәмлегенең Кырынды авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, I төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнар (80 яшькә җиткән), студентлардан тыш, көндезге формада белем алучы гражданнардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатыннарын, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юллау белән килешәсезме:

1. Кырынды авылы урамнары юлларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (юлларны кардан чистарту, авыл җирлеге территориясендә үлән һәм чүп үләннәрен чаптыру, ягулык-майлау материаллары һәм тракторга запас частьләр сатып алу).

2. Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Кырынды торак пункты суын анализлау өчен түләү, тирәнлек насослары сатып алу).

3. Урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (урам яктырту өчен электр товарларын сатып алу, урнаштыру һәм алыштыру)ремонтлау.

4. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Кырынды авыл мәдәният йорты өчен янгын сүндерү җиһазлары сатып алу)

5. Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (рөхсәтсез чүплекләрне бетерү, Кырынды торак пунктында кешеләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырган аварияле һәм коры яшеллекләрне кисү, гараж территориясе алдын төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Кырынды авылы, Совет ур., 33 йорт, авыл мәдәният йорты бинасы.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль

берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль
районының Кырынды авыл җирлеге
башлыгы урынбасары: Р.М.Алиева